РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

___________________ №__________

Саба муниципаль районы территориясендә
стационар булмаган сәүдә объектларын
урнаштыру схемасын раслау турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 маддәсе, “Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләти җайга салуы нигезләре турында” 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль законның 10 маддәсе, “Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары тарафыннан стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында" 2011 елның 16 февралендәге 34-ОД номерлы Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры боерыгы һәм “Муниципаль милектә булган җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру Тәртибен раслау турында" 2016 елның 13 августындагы 553 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карары нигезендә Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ЧЫГАРА:

1. Саба муниципаль районы территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын расларга (бирелә);
2. Саба муниципаль районы Башкарма комитетының “Саба муниципаль районы территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын раслау турында" 2016 елның 17 ноябрендәге 1404-п номерлы карары үз көчен югалткан дип санарга;
3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Саба муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://saby.tatarstan.ru.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Саба муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары – икътисад бүлеге начальнигы М.М. Бaһмановка йөкләргә.

Җитәкче М.Р. Ишниязов